БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«04» 06 2021 ел № 183

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен вакытында карау максатларында, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелә торган Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү тәртибен расларга.

2. Сишәмбе 8.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан гражданнарны кабул итү көне дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетында гражданнарны шәхсән кабул итүгә шулай ук җавап хатларына имза куюга - Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә, Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына, Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына үз компетенцияләре кысаларында вәкаләт бирергә.

4. Җаваплы итеп түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына почта элемтәсе, электрон документлар әйләнеше системасында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Интернет-кабул итү аша гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне вакытында теркәү һәм гражданнарны кабул итү карточкаларын дөрес тутыру һәм алып бару өчен – гомуми-оештыру бүлегенең әйдәп баручы белгечен;

- Балтач район башкарама комитеты җитәкчесе, аның урынбасарлары тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итүне оештыру һәм гражданнарның телдән, язма мөрәҗәгатьләрен һәм «кайнар линия» телефоны буенча кабул

ителгән мөрәҗәгатьләрен вакытында карауны һәм үтәлешен контрольдә тоту өчен - гомуми-оештыру бүлеге башлыгын;

- гражданнарның телдән, язма мөрәҗәгатьләренә һәм «кайнар линия» телефоны буенча кабул ителгән мөрәҗәгатьләренә җавапларны вакытында җибәрүне контрольдә тоту өчен - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының гомуми-оештыру бүлегенең әйдәп баручы белгечен.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

6. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итү тәртибен раслау турында» 2019 елның 14 октябрендәге 323 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының гомуми-оештыру бүлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов

Балтач район башкарма комитетының
2021 елның «04» 06. _
183 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе гражданнарының язмача һәм телдән мөрәҗәгатьләрен кабул итү, исәпкә алу, теркәү, карау, аларны карау һәм аларның үтәлешен контрольдә тоту кагыйдәләрен билгели, мөрәҗәгатьләрдә булган мәгълүматны анализлау һәм гомумиләштерү, мөрәҗәгатьләрнең сәбәпләрен һәм характерын ачыклау, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетында (алга таба – башкарма комитет) гражданнарны кабул итүне оештыру тәртибен билгели.

Әлеге Тәртип нигезләмәләре «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - Федераль закон) һәм «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә каралырга тиешле барлык мөрәҗәгатьләргә кагыла.

1.2. Гражданнарның язмача мөрәҗәгатьләре тәкъдимнәр, гаризалар һәм шикаятьләр рәвешендә керә.

Гражданның язма рәвештә бәян ителгән мөрәҗәгатендә я мөрәҗәгать юллана торган җирле үзидарә органының исеме һәм адресы, я тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, я тиешле затның вазыйфасы, шулай ук тәкъдим, гариза яки шикаятьнең асылын бәян итү, үз фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), җавап, мөрәҗәгатьне башкаларга җибәрү турында хәбәрнамә җибәрелергә тиешле почта адресы, шәхси имза һәм дата булырга тиеш.

Кирәк булган очракта, үз дәлилләрен раслау өчен граждан язма мөрәҗәгатькә документларны һәм материалларны яки аларның күчермәләрен беркетеп бирә.

Җирле үзидарә органнарына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан мәҗбүри рәвештә үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта), җавап, мөрәҗәгатьне башкага җибәрү турында хәбәрнамә җибәрелергә тиешле электрон почта адресын күрсәтә. Граждан мондый мөрәҗәгатькә электрон формада кирәкле документларны һәм материалларны беркетергә хокуклы.

Гражданнар Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, туган телдә яисә Россия Федерациясе халыкларының теләсә кайсы башка телендә тәкъдимнәр, гаризалар, шикаятьләр белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Гражданнардан кергән тәкъдимнәргә, гаризаларга, шикаятьләргә җаваплар мөрәҗәгать итү

телендә бирелә. Мөрәҗәгать итү телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

1.3. Башкарма комитет яисә вазыйфаи зат компетенциясенә керми торган мәсьәләләрне хәл итү кирәк булган мәсьәләләрне үз эченә алган язма мөрәҗәгатьләр, аларны теркәгәннән соң җиде көн эчендә, Федераль законның 11 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш, мөрәҗәгатьне башкаларга җибәрү турында мөрәҗәгать юллаган гражданга хәбәр итү белән, мөрәҗәгатьләрдә куелган мәсьәләләрне хәл итү алар компетенциясенә кергән тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрелә. Шул ук вакытта хәбәрнамәнең текстында Законның тиешле сттатьясына сылтама булырга тиеш. Хәбәрнамәнең икенче нөсхәсе эшкә беркетелә.

Миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозу фактлары турында мәгълүматны үз эченә алган язма мөрәҗәгать, Федераль законның 11 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш, аның мөрәҗәгатен башкаларга җибәрү турында мөрәҗәгать җибәргән гражданга хәбәр итү белән, теркәлгән көннән биш көн эчендә эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органына һәм Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

Язма мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү берничә дәүләт органы, җирле үзидарә органнары яки вазыйфаи зат компетенциясенә керсә, мөрәҗәгатьнең күчермәсе теркәлгән көннән җиде көн эчендә тиешле дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә тиешле вазыйфаи затларга җибәрелә.

1.4. Карарына яисә гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка шикаятьне карау өчен җибәрү тыела.

Әгәр моңа бәйле рәвештә мөрәҗәгатьләрдә куелган мәсьәләләрне хәл итү алар компетенциясенә кергән дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка шикаятьне җибәрү мөмкин булмаса, тиешле карарга яки гамәлгә (гамәл кылмавына) билгеләнгән тәртиптә судка шикаять белдерү хокукын аңлатып, шикаять гражданга кире кайтарыла.

1.5. Әгәр язма мөрәҗәгать тексты укып аңларлык булмаса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә карау өчен җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәгән көннән җиде көн эчендә, әгәр мөрәҗәгать итүче гражданның фамилиясе һәм почта адресы укып аңларлык булса, аңа хәбәр ителә. Күрсәтелгән мөрәҗәгать эшкә беркетелә.

Язма мөрәҗәгать тексты буенча тәкъдимнең, гаризаның яки шикаятьнең асылын билгеләп булмаса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә карап тикшерү өчен җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга хәбәр ителә.

1.6. Мөрәҗәгать җибәргән гражданның фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы булмаган язма мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Мондый мөрәҗәгать тиешле эшкә беркетелә. Әгәр күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, кылына торган яки кылынган хокукка каршы

гамәл, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яки башкарган зат турында белешмәләр булса, мөрәҗәгать компетенциясе буенча тиешле дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

1.7. Гражданнар башкарма комитетка, башкарма комитетның вазыйфаи затларына үз вәкиле аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.8. Суд карарына шикаять бирелә торган мөрәҗәгать, теркәлгән көннән җиде көн эчендә, әлеге суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать җибәргән гражданга кире кайтарыла.

1.9. Әгәр кергән язма мөрәҗәгатьтә әдәпсез яисә мәсхәрәле сүзләр, башкарма комитетның вазыйфаи затының, шулай ук аның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян китерү белән янаулар булса, ул анда куелган сорауларның асылы буенча җавапсыз калдырылырга мөмкин. Бу очракта мөрәҗәгать җибәргән гражданга мөрәҗәгать итү хокукын явыз ният белән файдалану ярамау турында хәбәр ителә.

1.10. Гражданның язма мөрәҗәгатендә элегрәк җибәрелгән мөрәҗәгатьләргә бәйле рәвештә асылы буенча күп тапкырлар язма җаваплар бирелгән сорау булса, шул ук вакытта мөрәҗәгатьтә яңа дәлилләр яки хәлләр китерелми икән, әгәр күрсәтелгән мөрәҗәгать һәм элегрәк җибәрелә торган мөрәҗәгатьләр берничә тапкыр башкарма комитетка яисә бер үк вазыйфаи затка юлланган булса, Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе әлеге мәсьәлә буенча чираттагы мөрәҗәгатьнең нигезсез булуы һәм граждан белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Мөрәҗәгать җибәргән гражданга әлеге карар турында хәбәр ителә.

1.11. Башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка җавабы Федераль законның 10 статьясындагы 4 өлеше һәм әлеге Тәртипнең 2.12 пунктындагы бишенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган язмача мөрәҗәгать кергән очракта, мөрәҗәгать иткән гражданга мөрәҗәгать теркәлгән көннән җиде көн эчендә мөрәҗәгатьтә куелган сорауга җавап урнаштырылган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә, шул ук вакытта суд карарына шикаять белдерүче мөрәҗәгать кире кайтмый.

1.12. Мөрәҗәгатьтә куелган сорауның асылы буенча җавап дәүләт серен яисә федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрне читкә сөйләмичә генә бирелә алмаса, мөрәҗәгать җибәргән гражданга күрсәтелгән белешмәләрне ачу тыелган булу сәбәпле, анда куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә.

1.13. Мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча җавап биреп булмауның сәбәпләре алга таба бетерелгән очракта, граждан яңадан җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка мөрәҗәгать җибәрергә хокуклы.

## 2. Гражданнарның язма мөрәҗәгатьләрен кабул итү, теркәү һәм исәпкә алу

2.1. Почта аша җибәрелгән әйберләрдә булырга мөмкин булган

шартлаткыч, агулы һәм башка куркыныч кушып салынган әйберләрне вакытында ачыклау һәм зарарсызландыру максатларында, аларны тышкы яктан карап тикшерәләр. Мондый кушып салынган әйберләр ачыкланган очракта яки алар булу-булмауга шик туса, почта аша җибәрүләр белән алга таба эшләү кичекмәстән туктатыла һәм куркынычсызлык органының тиешле бүлекчәсе белгече чакырыла. Белгеч чакырту белән бер үк вакытта почта аша җибәрелгән әйберне мәҗбүри изоляцияләү белән куркынычсызлык чаралары күрелергә тиеш.

Террорчылык актлары һәм башка җинаятьләрне кылу белән янаулар булган язма мөрәҗәгатьләрне алганда, оператив-эзләү чараларын һәм тикшерү гамәлләрен үткәргәндә файдаланылырга мөмкин булган эзләрне саклау өчен чаралар күрелә.

2.2. Язма мөрәҗәгатьләрне кабул иткәндә аларның адресларының дөреслеге тикшерелә. Билгеләнеше буенча килмәгән хатлар адресатка җибәрү өчен кичекмәстән элемтәнең почта предприятиесенә ачылмаган килеш кире кайтарыла.

Конвертларны ачканда аларда хат һәм документлар булуы тикшерелә (ертылган документлар ябыштырыла), алар конверт белән беркетелә, кергән документлар (паспорт, хәрби билет, хезмәт кенәгәсе, пенсия таныклыгы һ.б., шулай ук фотосурәтләр һәм хатка башка кушымталар) хат тексты алдыннан беркетелә. Кушымта яки хат тексты булмаган очракта, конвертка кушып бирелә торган белешмә куела һәм бу хакта гариза бирүчегә хәбәр ителә.

2.3. Барлык язма мөрәҗәгатьләр башкарма комитетка кергәннән соң өч көн эчендә теркәлә. Һәр мөрәҗәгатькә тәртип буенча теркәү номеры бирелә. Һәр яңа календарь елында яңадан кергән мөрәҗәгатьләрнең номерлары беренче номердан башлана. Теркәлгәннән соң, кергән барлык мөрәҗәгатьләрне дә аларда булган мәгълүмат предметына алдан карап тикшерү оештырыла. Әлеге процедураның максаты - башкарма комитетка коррупция фактлары буенча гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр санын билгеләү.

Кергән корреспонденциядән мөмкин булган коррупцион хокук бозулар турында мәгълүмат булган мөрәҗәгатьләр ачыклана (муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренең (гамәл кылмавының) гражданнарның законлы мәнфәгатьләренә карамастан, үзе өчен яисә өченче затлар өчен акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт яисә мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләр рәвешендә табыш алу максатларында, вазыйфасыннан законсыз файдалануга бәйле булуын күрсәтүче факттагы мәгълүматлар).

Әлеге процедура әлеге Тәртипнең 3 бүлегендә каралган аерым тәртиптә карала торган мөрәҗәгатьләрне ачыкларга мөмкинлек бирә.

2.5. Башкарма комитетка кәгазь чыганакта кергән язма мөрәҗәгатьләр мәҗбүри рәвештә сканерлана һәм электрон документлар әйләнеше системасына йөкләнә.

2.6. Граждан шикаятендә күрсәтелгән белешмәләр ахыргы карарны чыгару өчен җитәрлек булмаса, гамәлләренә карата шикаять белдерелгән учреждениедән яисә заттан карар кабул итүнең нигезлелеге турында бәяләмә белән тикшерү материаллары соратып алына. Кирәк булган очракта, Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе буенча шикаятьләр урынга

чыгып тикшерелергә мөмкин.

2.7. Әгәр барлык сораулар каралган, алар буенча тиешле чаралар күрелгән һәм гамәлдәге законнарга туры килә торган тулы җаваплар бирелгән булса, гражданнарның хатлары хәл ителгән дип санала.

2.8. Башкаручы (имза куйган затлар белән бер үк вакытта) җавапларның эчтәлеге, ачыклыгы һәм төгәллеге, норматив актларга сылтамаларның дөреслеге өчен җаваплы.

2.9. Башкарма комитетның вазыйфаи затлары:

а) мөрәҗәгатьне объектив, һәрьяклы һәм вакытында, кирәк очракта - мөрәҗәгать җибәргән граждан катнашында карауны тәэмин итәләр;

б) мөрәҗәгатьне карау өчен кирәкле документларны һәм материалларны, шул исәптән электрон формада, башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм башка вазыйфаи затлардан, судлардан, сорау алу органнарыннан һәм алдан тикшерү органнарыннан тыш, соратып алалар;

в) гражданның бозылган хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызуга яисә яклауга юнәлдерелгән чаралар күрәләр;

г) әлеге Тәртипнең 1.5, 1.6, 1.8, 1.9, 1.10, 1.11, 1.12, 1.13 пунктларында күрсәтелгән очраклардан тыш, мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язма җаваплар бирәләр;

д) гражданга аның мөрәҗәгатен башка дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә башка вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә карау өчен җибәрү турында хәбәр итәләр.

2.10. Мөрәҗәгатьне караганда, мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне, шулай ук гражданның шәхси тормышына кагылышлы белешмәләрне аның ризалыгыннан башка читкә сөйләү рөхсәт ителми. Мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма мөрәҗәгатьне җибәрү белешмәләрне читкә сөйләү булып тормый.

2.11. Башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә кергән язма мөрәҗәгатьләр, Федераль законның 12 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш, язма мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып 30 көн эчендә карала.

2.12. Башкарма комитетка кергән мөрәҗәгатьләрне карау вакыты башлану дип аларның теркәү көне санала. Мөрәҗәгатьләрне карау вакыты тәмамлану дип мөрәҗәгать авторына җавап бирү датасы санала.

2.13. Билгеләнгән тәртиптә каралган мөрәҗәгатьләр буенча карарлар чикләнгән таратулы хезмәт мәгълүматына кертелергә мөмкин түгел.

Мөрәҗәгатьтә куелган сорауның асылы буенча җавап дәүләт серен яисә федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрне читкә сөйләмичә генә бирелә алмаса, мөрәҗәгать җибәргән гражданга күрсәтелгән белешмәләрне ачу тыелган булу сәбәпле, анда куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә.

2.14. Язма мөрәҗәгатькә җавап Балтач район башкарма комитеты бланкында яки район Советы бланкында әзерләнә һәм Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе, аның урынбасарлары тарафыннан аларның компетенциясе нигезендә имзалана. Җавап граждан күрсәткән адреска

җибәрелә.

Ике һәм аннан күбрәк зат мөрәҗәгатенә (коллектив мөрәҗәгатькә) җавап алучы яисә мөрәҗәгатькә имза куйган гражданнар коллективы вәкиле буларак мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән затка җибәрелә. Әгәр җавап алучы коллектив мөрәҗәгатьтә билгеләнмәгән булса, җавап яшәү урынын күрсәткән мөрәҗәгать итүчеләр (имза куючылар) исемлегендә беренче торган гражданга җибәрелә. Коллектив мөрәҗәгатькә җавап җибәрү турындагы үтенеч берничә мөрәҗәгать итүче (имза куючы) зат тарафыннан белдерелгән очракта, җавапның күчермәсе аларның һәркайсына күрсәтелгән почта адреслары буенча җибәрелә.

Башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә килгән мөрәҗәгатькә җавап электрон документ рәвешендә мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча һәм башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка язма рәвештә кергән мөрәҗәгатькә - мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә. Моннан тыш, башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка кергән, билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагылышлы тәкъдимне, гаризаны яки шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатькә, аерым алганда, билгесез затлар даирәсенә карата чыгарылган суд карарына, шул исәптән суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатуга бәйле мөрәҗәгатькә җавап, Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлеше һәм әлеге Тәртипнең 2.11 пункты таләпләрен үтәп, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин.

### 3. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе

3.1. Алдан карап тикшерү процедурасын уздырганнан соң коррупциягә каршы хокук бозулар турында мәгълүмат ачыкланган мөрәҗәгать кичекмәстән Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә тапшырыла.

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе резолюция сала һәм башкаручыларны билгели. Мөрәҗәгатьне карау махсус контрольгә алына.

3.2. Мөрәҗәгать карары яисә гамәле (гамәл кылмавы) мөрәҗәгать итү предметы булган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка җибәрелми.

3.3. Күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, кылына торган яки кылынган хокукка каршы гамәл, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яки башкарган зат турында белешмәләр булган очракта, мөрәҗәгать теркәлә һәм компетенциясе нигезендә дәүләт органына җибәрелә.

Мөрәҗәгатьтә муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәт белән бәйле вазыйфаларны, чикләүләрне һәм тыюларны, шулай ук хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәмәү, муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы булу турында, мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү турында, муниципаль хезмәткәрнең башка коррупцион хокук бозуларны кылу ихтималы турында

белешмәләр булса, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәсе вазыйфаи затының (коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазыйфаи затларның) доклад язмасы нигезендә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактларга карата тикшерү үткәрүнең максатчанлыгы турында карар кабул итә. Әлеге тикшерү хезмәт тәртибе таләпләренең (муниципаль хезмәткәр тарафыннан чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәү, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларны үтәү) үтәлешен тикшерү булып тора һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә уздырыла.

3.4. Мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар оператив-эзләү чараларын үткәрү юлы белән тикшерүгә мохтаҗ булса, мөрәҗәгатьне карау барышында оператив-эзләү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле дәүләт органнарына гарызнамә җибәрелә.

3.5. Күрсәтелгән тикшерүне уздырганда муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәве турында дәлилләүче фактлар ачыкланса, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиягә (алга таба - Комиссия) тикшерү материаллары тапшыру турында карар кабул итә.

Әлеге мәсьәләне Комиссия утырышында карау турында карар кабул ителгәндә, утырышның датасы, вакыты һәм урыны билгеләнә, шулай ук хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия Нигезләмәсе нигезендә Комиссия утырышын әзерләү эше оештырыла.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча җавапта үткәрелгән чаралар һәм тикшерүләр нәтиҗәләре, Комиссия карарлары (булган очракта) турында мәгълүмат, шулай ук кабул ителгән чаралар, шул исәптән муниципаль хезмәткәргә карата җаваплылык чараларын куллану яисә тикшерү үткәрү өчен нигезләрнең булмавы һәм коррупция фактлары расланмау турында мәгълүмат булырга тиеш.

3.7. Башкарма комитетка кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре әлеге Тәртиптә билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш.

3.8. Мөрәҗәгать гражданинга мөрәҗәгатьтә куелган барлык сорауларга җавап җибәргәннән соң контрольдән алына.

## 4. Гражданнарны шәхси кабул итүне оештыру

4.1. Гражданнарны шәхси кабул итү Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе, аның урынбасарлары тарафыннан

үткәрелә.

Башкарма комитетта гражданнарны кабул итү 111 нче кабинетта һәм урынбасарларның хезмәт кабинетларында башкарыла. Кирәк булганда, очрашулар гражданнарның яшәү яки эш урыннары буенча оештырыла.

4.2. Кабул итү урыны, кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр, гражданнарны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи затларның телефон номерлары турында мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка җиткерелә һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

Әлеге мәгълүмат шулай ук түбәндәге адрес буенча урнашкан Балтач район башкарма комитеты бинасының 1 нче катындагы мәгълүмат стендында да урнаштырыла: ТР, Балтач районы, Балтач штп., Ленин урамы, 42 нче йорт.

Кабул ителә торган бинада гражданнарны кабул итүгә турыдан-туры катнашы булмаган затларга булу тыела.

4.3. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең кабул итү бүлмәсендә телдән мөрәҗәгатьләрнең эчтәлеге гражданның шәхси кабул итү карточкасына кертелә (2 нче кушымта), анда гражданны кабул итү датасы, аның фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта), аның яшәү урыны адресы, кабул итүне алып баручы вазыйфаи (вәкаләтле) затның фамилиясе, телдән мөрәҗәгатьнең эчтәлеге һәм аның буенча кабул ителгән чаралар турында белешмәләр булырга тиеш. Күрсәтелгән реквизитлар башка кирәкле мәгълүматлар белән тулыландырылырга мөмкин.

4.4. Түбәндәге затлар гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә беренче чиратта шәхси кабул ителү хокукына ия:

1) I, II төркем инвалидлар һәм (яки) аларның законлы вәкилләре (ата-аналарның берсе, уллыкка алучылар, опекун яки попечитель);

2) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясенең Хезмәт Геройлары, хәрби хәрәкәтләр ветераннары;

3) инвалид балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, шулай ук мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр, аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре;

4) өч яшькә кадәрге балалар белән кабул итүгә килгән гражданнар;

5) Балтач муниципаль районының Мактаулы гражданнары.

4.5. Шәхси кабул итү вакытында граждан шәхесен раслаучы документ күрсәтә. Әлеге Тәртипнең 4.4 пунктының 1-5 бүлекләрендә күрсәтелгән гражданнарны шәхси кабул иткәндә, аларны беренче чиратта шәхси кабул ителүгә хокукын раслаучы документ күрсәтәләр. Беренче чиратта шәхси кабул ителү хокукына бр үк вакытта берничә граждан ия булса, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килү тәртибендә гамәлгә ашырыла.

4.6. Кабул итүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи (яисә вәкаләтле) зат гражданны игътибар белән тыңларга һәм мөрәҗәгатенең асылын җентекләп

тикшерергә тиеш, телдән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар һәм хәлләр ачык күренеп торган һәм өстәмә тикшерүне таләп итмәгән очракта, гражданның ризалыгы белән мөрәҗәгать итүгә җавап шәхси кабул итү барышында телдән бирелергә мөмкин, бу хакта гражданны шәхси кабул итү карточкасында язып куела һәм граждан имзасы белән раслана. Калган очракларда мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача җавап бирелә.

Шәхси кабул итү барышында кабул ителгән язма мөрәҗәгать Федераль законда һәм әлеге Тәртиптә билгеләнгән тәртиптә теркәлергә һәм каралырга тиеш.

Мөрәҗәгатьтә башкарма комитет яисә вазыйфаи зат компетенциясенә керми торган мәсьәләләр булган очракта, гражданга кая һәм нинди тәртиптә мөрәҗәгать итәргә кирәклеге турында аңлатма бирелә.

Шәхси кабул итү барышында гражданга, әгәр элегрәк мөрәҗәгать итүдә куелган сорауларның асылы буенча җавап бирелгән булса, алга таба мөрәҗәгатьләрне караудан баш тартырга мөмкин.

4.7. Башкарма комитетның вазыйфаи затлары гражданнарны шәхси кабул итүгә бәйле мәсьәләләр буенча җирле үзидарәнең башка органнарына, предприятиеләргә, учреждениеләргә яисә оешмаларга мөрәҗәгать итәргә хокуклы, аларның җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре аларга ярдәм күрсәтергә һәм булышырга тиеш: кирәкле белешмә һәм мәгълүмат материалларын (норматив хокукый актлар нигезендә хәбәр ителергә тиешле белешмәләрдән тыш) тапшырырга, квалификацияле консультацияләр, элемтә белән тәэмин итәргә, кабул итү өчен хезмәткәрләрне җибәрергә һ.б.

4.8. Граждан кабул итү бүлмәсендә әйләнә-тирәдәгеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч тудыручы гамәлләр кылган очракта, кабул итүне алып баручы вазыйфаи (яисә вәкаләтле) зат Россия Федерациясе законнары нигезендә тиешле чаралар күрә. Кирәк булганда эчке эшләр һәм ашыгыч медицина ярдәме органнары хезмәткәрләре чакырыла.

## 5. Мөрәҗәгатьләр белән эш торышын тикшерү һәм аларны карауны контрольдә тоту Мөрәҗәгатьләрдәге мәгълүматны анализлау һәм гомумиләштерү

5.1. Башкарма комитетның вазыйфаи затлары үз компетенциясе кысаларында мөрәҗәгатьләрне карау тәртибенең үтәлешен контрольдә тоталар, кергән мөрәҗәгатьләрнең эчтәлеген анализлыйлар, гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу сәбәпләрен вакытында ачыклау һәм бетерү буенча чаралар күрәләр.

5.2. Анализ үткәргәндә кергән, башкаларга җибәрелгән һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләрнең саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый һәм башка актлар (булганда) турында мәгълүмат өйрәнелә.

5.3. Башкарма комитетта барлык язма мөрәҗәгатьләр, шулай ук гражданнарны шәхси кабул итүдә мөрәҗәгатьләр башкару вакытлары буенча контрольгә алынырга тиеш, аларны карау нәтиҗәләре турында авторга җавап бирергә яисә тиешле орган яисә вазыйфаи зат гарызнамәсе буенча мәгълүмат бирергә кирәк.

5.4. Контроль буенча турыдан-туры эш башкарма комитетның контроль буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи затларына йөкләнә.

Мондый контрольне гамәлгә ашыручы затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

а) башкаручылардан һәм аларның турыдан-туры җитәкчеләреннән мөрәҗәгатьләрне карау барышы турында кирәкле мәгълүматларны соратып алырга;

б) билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгатьләрне карау торышын чагылдыручы материаллар белән танышырга;

в) мөрәҗәгатьләрне карау барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча тиешле вазыйфаи затларга тәкъдимнәр кертергә.

5.5. Мөрәҗәгатьләрне карауның барышы турында даими рәвештә, ләкин айга кимендә бер тапкыр, Башкарма комитетта хәбәр итәргә.

5.6. Мөрәҗәгатьләр белән эшләүнең торышы (гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ) шулай ук Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе эшчәнлеге турында еллык хисапларда чагылдырыла һәм мәҗбүри тәртиптә муниципаль районның Интернет челтәрендәге рәсми сайтына кушымта итеп бирелгән форма буенча (3, 4 кушымталар) урнаштырыла.

5.7. Аналитик эш Балтач район башкарма комитетының барлык бүлекчәләре белән тыгыз элемтәдә алып барыла. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен караучы белгечләр даими рәвештә үзләренә беркетелгән территориядә тематик язмалар, башка аналитик материаллар язу өчен материаллар (мөрәҗәгатьләрнең, җавапларның күчермәләрен ясыйлар) сайлап алуны һәм туплауны алып баралар, аналитик материаллар төзү өчен кирәкле мәгълүматны вакытында әзерлиләр.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетында
гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча
эш һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин
итү тәртибенә
1 нче кушымта

Гражданнарның телдән мөрәҗәгатьләрен теркәү журналы

| № т/б | Мөрәҗәгать итү датасы | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Яшәү адресы | Эшчәнлекнең төре | Телдән мөрәҗәгатьнең кыскача эчтәлеге | Кемгә адресланган, карау нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү тәртибенә
2 нче кушымта

**ГРАЖДАННАРНЫ КАБУЛ ИТҮНЕҢ УЧЕТКА АЛУ КАРТАСЫ**

№_______ Кабул итү көне 20_____ елның «_____»_________________________

Район_____________________________________________________________

Адрес_____________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

Авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

Социаль хәле ______________________________________________________

Ташламалы состав___________________________________________________

Кабатлау: Әйе, юк __________________________________________________

Әңгәмәнең эчтәлеге _________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

Кабул итү нәтиҗәсе _________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

Әңгәмәне алып барды

__________________________________________________________________

Имза ______________________________________________________________

Телдән җавапка риза ________________________________________________

Имза ______________________________________________________________

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетында
гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча
эш һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин
итү тәртибенә
3 нче кушымта

**Балтач муниципаль районы органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында СТАТИСТИК МӘГЪЛӘМАТЛАР**

| Районнар һәм шәһәрләр исеме | Кергән барлык мөрәҗәгатьләр (язмача һәм телдән мөрәҗәгатьләр)* | | Кергән электрон мөрәҗәгатьләр (Интернет- кабул итү, электрон почта)* | | Шул исәптән җитәкчелеккә**** хәбәр ителде | | Контрольгә алынды | | Уңай карар чыгарылды | | Урынга чыгып тикшерелде | | Шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар | | Шул исәптән җитәкчелек*** тарафыннан | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 20 ел | 20 ел | 20 ел | 20 ел | 20 ел | 20 ел | 20 ел | 20 ел | 20 ел | 20 ел | 20 ел | 20 ел | 20 ел | 20 ел | 20 ел | 20 ел |
| Балтач муниципаль районы | | | | | | | | | | | | | | | | |

Искәрмә:

*Телдән мөрәҗәгатьләр: шәхси кабул итү һәм телефоннан шалтыратулар.

** Электрон мөрәҗәгатьләр язма мөрәҗәгатьләр исәбенә керә.

*** Җитәкчелек - муниципаль берәмлек башлыгы һәм муниципаль берәмлек башкарма комитеты җитәкчесе